Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының утыз алтынчы утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

23 ноябрь, 2023 ел № 281

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставы нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» 2016 елның 19 апрелендәге 38 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карары белән (Питрәч муниципаль районы Советының 2017 елның 13 июлендәге 101 номерлы, 2017 елның 14 сентябрендәге 111 номерлы, 2018 елның 26 апрелендәге 141 номерлы, 2018 елның 24 октябрендәге 164 номерлы, 2019 елның 28 февралендәге 184 номерлы, 2019 елның 25 июлендәге 212 номерлы, 2020 елның 26 мартындагы 249 номерлы, 2020 елның 14 маендагы 263 номерлы, 2021 елның 22 июлендәге 49 елның 22 мартындагы 151 номерлы, 2021 елның 10 августындагы 250 номерлы карарлары белән расланган үзгәрешләр белән), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә 1 нче кушымтада:

а) 11 өлештә икенче җөмләне төшереп калдырырга;

б) 17 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

в) 20 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20. Муниципаль хезмәткәргә класслы чин бирү турындагы карар, әлеге Нигезләмәнең 13 өлешендә күрсәтелгән очраклардан тыш, җирле үзидарәнең органына яисә вазыйфаи затына барлык кирәкле документлары булган класслы чин бирү турындагы тәкъдим кертелгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов